ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№2** **2015 елнын 2 феврале**

# Финанс кризисы шартларында Түбән Кама муниципаль районында социаль-икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү буенча комиссия составын раслау турында

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә финанс кризисының тискәре нәтиҗәләрен бетерү, икътисад тармакларының икътисадый тигезлеген һәм тотрыклы эшләвен тәэмин итү, халыкның мәшгульлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары, эшкуарлык җәмәгатьчелеге белән финанс, икътисади, җитештерү һәм социаль өлкәләрдә кризиска каршы чараларны гамәлгә ашырганда үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Финанс кризисы шартларында Түбән Кама муниципаль районында социаль-икътисади тотрыклылык буенча комиссия төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2 нче кушымта нигезендә, финанс кризисы шартларында Түбән Кама муниципаль районында социаль - икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Р. Метшин

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгының 2015 елның
2 февралендәге 2 номерлы карары
белән расланган
1 нче кушымта

**Кризис шартларында Түбән Кама муниципаль районында социаль-икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Метшин А.Р. | комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы; |
| Бит-Мирза О.Д. | комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча); |
| Сотин И.А. | комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча). |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Долотказина Э. Р. | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Камалетдинов Т.Х. | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Гәрәев А.Ф. | Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Сперанский М. В. | Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы киңәшчесе (килешенү буенча); |
| Федотов В. В. | Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча); |
| Нигъмәтҗанов А.Г. | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча); |
| Юнысов Л.Р. | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча); |
| Тартмина Л.М. | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыру һәм муниципальара хезмәттәшлек буенча идарә башлыгы (килешенү буенча); |
| Логинова С.Н. | Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Бюджет һәм финанслар департаменты» МКУ башлыгы (килешенү буенча); |
| Бәйрәмов А. И. | Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәтенең 11 нче номерлы районара инспекциясе башлыгы (килешенү буенча); |
| Вәлиев Р.Ф. | Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча икътисади куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсенең «Түбән Кама шәһәре дислокациясе» бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча); |

| | |
|---|---|
| Семенова Л.Л. | дәүләт учреждениесе - Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм шәһәре буенча Россия Федерациясе Пенсия фонды бүлекчәсенең территориаль идарәсе җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Кадыйрова В.Н. | Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәте территориаль органының Түбән Кама дәүләт статистикасы бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Мөстәкыймов Ф.С. | Түбән Кама шәһәр прокуратурасы прокуроры, юстициянең өлкән киңәшчесе (килешенү буенча); |
| Соковых И.В. | «Түбән Кама мәшгульлек үзәге» ДБУ директоры (килешенү буенча); |
| Трошина Т.В. | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Түбән Кама муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе (килешенү буенча); |
| Җамалиева Г.М. | Татарстан Республикасы халыкны социаль яклау министрлыгының Түбән Кама районында һәм Түбән Кама шәһәрендә халыкны социаль яклау идарәсе башлыгы (килешенү буенча); |
| Фәйзрахманов Р.В. | Россия Федерациясе куркынычсызлык федераль хезмәте идарәсенең Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре буенча бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча); |
| Полякова Е.Р. | Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча 11 нче региональ бүлекчәсе дәүләт учреждениесе директоры (килешенү буенча); |
| Слободюк К.П. | Түбән Кама муниципаль районы буенча ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсе башлыгы (килешенү буенча); |
| Гыймалетдинов И.Т. | Афанас авыл җирлеге Советы депутаты, «Тимерхан» сәүдә комплексы генераль директоры (килешенү буенча); |
| Мостафин Р.М. | Бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссия рәисе, «РаМус» ҖЧҖ генераль директоры (килешенү буенча); |
| Бикмурзин А.Ш. | «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ генераль директоры (килешенү буенча); |
| Борһанов Р.Ф. | «Түбән Кама шин» ААҖ генераль директоры (килешенү буенча); |
| Алёхин Л.С. | «ТАНЕКО» ААҖ генераль директоры (килешенү буенча); |
| Шәмгунов Р.Р. | «ТАИФ-НК» ААҖ генераль директоры (килешенү буенча); |
| Вахитов А.Ф. | «Татнефть-Нефтехим» ИК директоры (килешенү буенча); |
| Будилкин В.В. | «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ директоры (килешенү буенча). |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгының 2015 елның
2 февралендәге 2 номерлы карары белән
расланган
2 нче кушымта

**Кризис шартларында Түбән Кама муниципаль районында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча комиссия турында нигезләмә**

**1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Финанс кризисы шартларында Түбән Кама муниципаль районында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) Түбән Кама муниципаль районы территориясендә дөньякүләм финанс кризисының тискәре нәтиҗәләрен бетерү, икътисад тармакларының икътисадый тигезлеген һәм тотрыклы эшләвен тәэмин итү, халыкның мәшгульлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары, эшкуарлык җәмәгатьчелеге белән финанс, икътисади, җитештерү һәм социаль өлкәләрдә кризиска кар шы чараларны гамәлгә ашырганда үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында максатларында төзелде.

1.2. Үз эшчәнлегендә комиссия Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Түбән Кама муниципаль районы, шәһәр муниципаль хокукый актларына (алга таба - муниципаль хокукый актлар), шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

**2 бүлек. Комиссиянең төп бурычлары һәм хокуклары**

2.1. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) халыкның ирешелгән тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүгә ярдәм итүче җирле үзидарә органнарының һәм хуҗалык субъектларының дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

б) кризис хәлен анализлау, аның тизрәк үтү чараларын эшләү;

в) икътисадның реаль һәм финанс секторларында, Түбән Кама муниципаль районының социаль өлкәсендә вәзгыятьне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

г) шәһәр оешмаларының һәм предприятиеләренең тотрыклы эшчәнлеге өчен чаралар эшләү, икътисадый үсешнең кимүенә юл куймау, куллланучылар ихтыяҗын саклап калу.

2.2. Аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен комиссия:

а) икътисадның реаль һәм финанс секторларында, шәһәрнең социаль өлкәсендә вәзгыятьне яхшыртуга юнәлтелгән чараларны эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда, анда тәкъдим ителгән органнарның эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

б) икътисадның реаль һәм финанс секторларында, шәһәрнең социаль өлкәсендә вәзгыятьне яхшыртуга юнәлдерелгән кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыруны даими контрольдә тотуны оештыра.

2.3. Комиссия хокуклы:

а) эшчәнлекнең барлык өлкәләренең икътисадын үстерүгә юнәлдерелгән карарлар проектларын әзерләүдә катнашырга;

б) билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

в) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кызыксынган оешмалар һәм эшкуарлык җәмәгатьчелеге вәкилләрен Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тыңларга һәм тиешле карарлар кабул итәргә;

г) Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларны үтәүгә кагылышлы мәсьәләләр буенча Комиссия әгъзаларын, бюджет барлыкка китерүче, шулай ук район икътисады өчен стратегик әһәмияткә ия оешмалар җитәкчеләрен тыңларга;

д) сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә, финанс-банк секторында, социаль өлкәдә һәм бәя сәясәтендә вәзгыятьне яхшыртуга юнәлдерелгән чараларны мониторинглау, эшләү һәм тормышка ашыру буенча, тиешле өлкәләрдәге вәзгыять һәм күрелә торган чаралар турында аларның көндәлек докладлары белән, даими эшләүче оператив штаблар булдыру.

## 3 нче бүлек. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретарь һәм комиссиянең башка әгъзаларыннан тора.

3.2. Комиссия рәисе:

1) Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

2) Комиссия составын аныклау һәм яңарту турында тәкъдимнәр кертә;

3) аның утырышларын алып бара;

4) сорауларны карау тәртибен билгели;

5) Комиссиянең эш планын раслый.

3.3. Комиссия рәисе булмаганда яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе вазыйфасын аның урынбасары башкара.

3.4. Комиссия утырышлары кирәк булганда үткәрелә. Комиссия утырышлары әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала. Комиссия әгъзалары алмаштыру хокукыннан башка комиссия утырышларында катнашалар.

3.5. Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

3.6. Комиссия утырышына Комиссия тарафыннан каралган мәсьәләләр алар компетенциясенә кергән органнар һәм оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре чакырыла.

3.7. Комиссия әгъзалары һәм чакырылганнар докладлар белән һәм ярдәмче докладлар белән чыгыш ясый алалар, фикер алышуларда катнаша, тәкъдимнәр кертә, тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы буенча белешмәләр бирә алалар.

3.8. Комиссиянең аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлары комиссиянең барлык әгъзалары һәм Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен мәҗбүри булып тора.

3.9. Комиссия карарлары Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзаланган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.